ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

15.11.2022 Казан ш. № 362-78/кс-2022

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 28.10.2020 №121-14/кс-2020 карарының 1 нче кушымтасына үзгәреш кертү турында һәм «СК-16» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен агып җыела торган суларны транспортлауга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 28.10.2020 №121-14/кс-2020 карары нигезендә билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2023 ел өчен үзгәреш кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 15 ноябрендәге 36-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә, билгеләнгән тарифлар кагыла торган кулланучыларны конкретлаштыру, 2023 елга җайга салынулы оешманың агып җыела торган суларны транспортлауга озак сроклы тарифларына һәм кирәкле тулай табышына төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының «СК-16» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен агып җыела торган суларны

транспортлауга 2021-2023 елларга тарифлар билгеләү турында» 28.10.2020 №121-14/кс-2020 карарының (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 10.12.2021 №511-169/кс-2021 карары керткән үзгәрешләре белән) 1 нче кушымтасына үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә бирергә (кушымтада бирелә).

2. Әлеге карар белән үзгәреш кертелгән 2023 елга тариф 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелә.

3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «СК-16» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен агып җыела торган суларны транспортлауга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 28.10.2020 №121-14/кс-2020 карары нигезендә билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2022 ел өчен үзгәреш кертү хакында» 10.12.2021 №511-169/кс-2021 карарын 2022 елның 1 декабреннән көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар 2022 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
28.10.2020 №121-14/кс-2020
карарына (Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
15.11.2022 № 362-78/кс-2022 карары
редакциясендә) 1 нче кушымта

Ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы «СК-16» ҖЧҖ өчен 2021-2023 елларга агып җыела торган суларны транспортлауга тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Агынты суларны транспортлауга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2021 ел | | 2022 ел | | 2023 ел |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 01.07.2022 башлап 30.11.2022 кадәр | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр |
| Казан шәһәре үзәкләштерелгән системасы зонасындагы кулланучылар | | | | | | |
| 1 | «СК-16» ҖЧҖ* | 7,99 | 7,99 | 7,99 | 7,99 | 8,44 |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге